**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 25 декабрендәге 5347 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 9 февралендәге 414 номерлы «Карл Маркс урамындагы җир кишәрлегенең бер өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Казан электр челтәрләре – «Челтәр компаниясе» акционерлык җәмгыяте филиалының Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 9 февралендәге 414 номерлы «Карл Маркс урамындагы җир кишәрлегенең бер өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы гаризасы нигезендә, 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»гы федераль законның 3.6 статьясына, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлегенә таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 9 февралендәге 414 номерлы «Карл Маркс урамындагы җир кишәрлегенең бер өлешенә ачык сервитут билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. 7.1 пунктчаны гамәлдән чыккан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**